ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
V чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
V созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
14.11.2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№02-10

## Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 04 декабряндәге 22-02 номерлы карары белән расланган Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында" 2025 елның 3 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 04 декабрендәге 22-02 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Актаныш муниципаль районы Советының 15.09.2018 № 30-07, 15.04.2019 № 37-06, 06.08.2019 № 39-09, 28.04.2020 № 46-08, 12.08.2020 № 47-07, 02.11.2020 № 02-09, 08.02.2021 № 07-08, 15.11.2021 № 12-11, 05.07.2023 № 30-08, 11.09.2023 № 31-04, 31.05.2024 № 36-05 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Нигезләмәнең II бүлеге 6 өлешендәге 6.6 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата:

югары белем булу - вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан тыш; югары белем яисә урта һөнәри белем булу- авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы:

Әйдәп баручы, өлкән һәм кече төркемнәрнең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнми.

Әлеге статья максатларында муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт вазыйфаларында һәм башка төр федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында эш стажы исәпкә алына.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Совет рәисе Л.Р.Зарипов